ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында” 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:
а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:
“Дәүләти-хосусый партнерлык концессия килешүен, тормыш циклы контрактын төзү һәм үтәү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин;”;
б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2) дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү (алга таба шулай ук – килешү) – гамәлдәге законнарда каралган төрле шартнамәләрнең элементлары кергән, дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары арасында төзелә һәм дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашырганда аларның хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын билгели торган шартнамә. Килешү яклары мөнәсәбәтләренә карата тиешле өлешләрдә элементлары килешүгә кергән шартнамәләр турында граждан законнары кагыйдәләре кулланыла;”;
в) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:
“Килешү гамәлдәге законнар нигезендә әйләнеше чикләнгән объектларга карата төзелә алмый;”;

2) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары**

1. Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма органы (алга таба – вәкаләтле орган), бер яктан, һәм хосусый партнер, икенче яктан, дәүләти-хосусый партнерлыкның субъектлары (килешү яклары) булалар.

2. Россиянең юридик яисә физик заты йә юридик зат төземичә генә гади ширкәт шартнамәсе (уртак эшчәнлек турында шартнамә) буенча эш итүче, эшчәнлеген килешү нигезендә гамәлгә ашыручы юридик затлар берләшмәсе хосусый партнер була ала, моңа түбәндәгеләр керми:

1) дәүләт компанияләре;

2) дәүләт корпорацияләре;

3) дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр;

4) дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр.

3. Чит илнең юридик яисә физик заты да, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, хосусый партнер була ала.

4. Әлеге статьяның 1 – 3 өлешләрендә күрсәтелгән затлар белән беррәттән муниципаль берәмлекләр исеменнән ихтыярый башлангычларда тиешле җирле үзидарә органнары, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары (килешү яклары) була ала.”;

3) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6 статья. **Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләре**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы финанс, мөлкәт рәвешләрендә, мәгълүмати ярдәм күрсәтү рәвешендә һәм законнарга, шул исәптән “Концессия килешүләре турында” Федераль законда каралган башка рәвешләргә каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта финанс рәвешендә катнашуы түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) хосусый партнерның килешүне үтәү өчен заем акчаларын җәлеп итүгә бәйле барлыкка килә торган йөкләмәләрне тиешенчә башкаруын тәэмин итүгә дәүләт гарантияләре бирү;

2) килешүне үтәгәндә алынмый калган керемнәрне каплау һәм (яисә) товарлар җитештерүгә (сатуга), эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләргә бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү (каплау) максатларында хосусый партнерга субсидияләр бирү;

3) хосусый партнерга – юридик затка бюджет инвестицияләре бирү;

4) проектлау алды һәм проектлау документларын эшләү, шулай ук килешү объектын булдыру, реконструкцияләү һәм (яисә) эксплуатацияләү чыгымнарын финанслау яисә финанслашу;

5) килешү шартлары нигезендә хосусый партнер мөлкәтен сатып алу;

6) килешүдә каралган һәм хосусый партнер җитештергән товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) билгеле күләмен җайга салына торган тарифлар (бәяләр) буенча түләү;

7) хосусый партнерның килешү объектын булдыруга яисә реконструкцияләүгә керткән акчаларын килешү шартлары нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтаруны тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта мөлкәт рәвешендә катнашуы түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) җир законнары нигезендә хосусый партнерга килешү объекты урнашкан яисә төзелә торган һәм (яисә) хосусый партнерның килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыруы өчен кирәкле җир кишәрлекләре бирү;

2) хосусый партнерга Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәткә ия булу һәм аннан файдалану хокукы бирү;

3) хосусый партнерның күчемсез (күчемле) мөлкәт объектын (килешү объектын) булдыру һәм (яисә) реконструкцияләү, аны алга таба эксплуатацияләвен килешүдә билгеләнгән тәртиптә, шартларда һәм вакыт дәвамында гамәлгә ашыру максатларында хосусый партнерга Татарстан Республикасы милкендәге башка күчемсез һәм (яисә) күчемле мөлкәтне йә Татарстан Республикасының махсус хокукларын ышанычлы идарәгә, алар белән эш итүгә һәм (яисә) алардан файдалануга тапшыру, бу вакыт тәмамлангач, хосусый партнер килешү объектын Татарстан Республикасы дәүләт милкенә тапшыра.

4. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта мәгълүмати ярдәм күрсәтү рәвешендә катнашуы региональ мәгълүмат системалары һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре булдыру яисә аларны бирү һәм аларның эшләвен тәэмин итү юлы белән, шулай ук законнарда тыелмаган башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Бер килешү кысаларында Татарстан Республикасы дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруның бер яисә берничә рәвешендә катнашырга мөмкин.

6. Дәүләти-хосусый партнерлык мөнәсәбәтләрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең катнашу рәвешләре, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.”;

4) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ статья өстәргә:

“$6^1$ статья. **Килешүнең эчтәлегенә таләпләр**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта әлеге Законда каралган рәвешләрдә катнашуы килешүләрдә түбәндәге шартларны мәҗбүри килештерү шарты белән гамәлгә ашырыла:

1) килешү объектын;

2) килешү объектына милек хокукын, шул исәптән килешү якларының килешү объектына милек хокукында өлешләр бүлүне, мондый хокук барлыкка килү шартларын һәм вакытын;

3) килешүнең гамәлдә булу срогын һәм (яисә) аны билгеләү тәртибен;

4) килешү яклары арасында исәп-хисаплар ясау, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендәге килешү объектыннан файдаланган өчен түләү тәртибен;

5) килешү яклары арасында ихтимал зыяннарны бүлү;

6) килешү якларының йөкләмәләрне үтәүләрен тәэмин итү ысулларын;

7) килешү шартларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыкны.

2. Дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган шартлардан тыш, килешүләрдә федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган теләсә кайсы башка шартларны, аерым алганда түбәндәгеләрне килештереп гамәлгә ашырыла:

1) килешү объекты Татарстан Республикасы милкенә тапшырылырга тиеш булган очракта, аның сыйфатына таләпләрне дә кертеп, килешү объектын Татарстан Республикасына тапшыру тәртибен һәм срокларын;

2) килешү объекты Татарстан Республикасы милкенә тапшырылырга тиеш булган очракта, Татарстан Республикасының килешү объектын киләчәктә куллануы максатларында мәгълүмат, мөлкәт һәм хокукларны, шул исәптән интеллектуаль милек хокукларын тапшыру тәртибен;

3) хосусый партнерның килешү нигезендә физик һәм юридик затларга товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) тапшыруын тәэмин итүен;

4) килешү объектын Татарстан Республикасы милкенә тапшыру вакытына кадәр аны килешү шартлары нигезендә эксплуатацияләү тәртибен;

5) килешү объектын булдыру, аңа хезмәт күрсәтү, аны реконструкцияләү, модернизацияләү һәм (яисә) эксплуатацияләү эшләрен башкару срогын, шулай ук бу килешүне озайту тәртибен;

6) хосусый партнерның килешү объектын залогка, башка йөкләмә хокукларында тапшыру йә кичектереп тору шартында сату мөмкинлеген, шулай ук аның хокукларын, шул исәптән, килешүдә билгеләнгән хәлләр барлыкка килгәндә, акчалата таләп буенча финанс шартнамәсе кысаларында өстәмә килешү төзеп тормыйча күчерү мөмкинлеген;

7) хосусый партнерның килешү объектын эксплуатацияләвен туктатуны (туктатып торуны) Татарстан Республикасы белән килештерү тәртибен һәм эксплуатацияләүне туктатканда яисә килешүне өзгәндә компенсацияләү тәртибен, мондый туктату (туктатып тору) җиңә алмаслык көчләр йогынтысына бәйле очраклардан, шулай ук Россия Федерациясе законнарында һәм килешүдә каралган башка очраклардан гайре;

8) хосусый партнерга килешү буенча хокукларны һәм бурычларны, шул исәптән бурычны таләп итү һәм (яисә) күчерү таләпләренә хокукны күчерү тәртибендә тапшыруга, шулай ук килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү максатларында килешү объектын залогка яисә башка хокукка тапшыруга ризалык бирү тәртибен;

9) килешүне үтәүгә бәйле зыяннарны һәм җаваплылыкны иминләштерүне;

10) килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәү өчен хосусый партнер тарафыннан җәлеп ителә торган өченче затларның килешүдә катнашуын хосусый партнерның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган белән килештерү бурычын;

11) килешү шартлары җитди бозылганда яисә килешүдә күрсәтелгән башка хәлләр барлыкка килгәндә, аерым алганда ихтимал зыянны яисә гадәттән тыш хәлләрнең куркыныч нәтиҗәләрен булдырмый калу, киметү яисә бетерү, физик һәм юридик затларның сәламәтлеген, иминлеген һәм мөлкәтләренең сакланышын, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү максатларында хосусый партнер белән килешүне өзү тәртибен;

12) финанс оешмасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган һәм (яисә) хосусый партнер арасында килешү объектына карата килешүләр төзү мөмкинлеген;

13) килешү объектына, килешү нигезендә башкарыла торган эшләргә яисә хезмәт күрсәтүләргә карата хосусый партнер ирешергә тиешле конкрет нәтиҗәләрне яисә күрсәткечләрне, аларга ирешү ысулларына бәйсез рәвештә, күрсәтү юлы белән хосусый партнерның бурычларын билгеләвен;

14) килешүне үтәү өчен хосусый партнерга бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге җир кишәрлекләре, күчемле һәм күчемсез милекнең башка объектлары, шулай ук хокуклар исемлеген;

15) килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен бирү тәртибен һәм хосусый партнер белән бу җир кишәрлекләрен арендалау (субарендалау) шартнамәләрен төзү срогын (җир кишәрлекләрен арендалау (субарендалау) шартнамәләрен төзү килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта);

16) килешү шартларын берьяклы үзгәртүнең һәм (яисә) аны үтәүдән берьяклы баш тартуның аерым очракларын;

17) федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка шартларны.

3. Җир кишәрлекләрен арендалау (субарендалау) шартнамәләре төзү килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, җир кишәрлеген арендалау (субарендалау) шартнамәсе, конкурс документларында башка сроклар билгеләнмәгән булса, хосусый партнер белән килешү имзаланган көннән алып алтмыш эш көненнән дә соңга калмыйча төзелергә тиеш.

4. Хосусый партнер җир кишәрлеген арендалау (субарендалау) шартнамәсе буенча хокукларын, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсендә бүтәне каралмаган булса, башка затларга тапшырырга һәм җир кишәрлеген субарендага бирергә тиеш түгел.

5. Килешүне өзү хосусый партнерга җир кишәрлегенә карата бирелгән хокукларны бетерү өчен нигез булып тора.

6. Килешү объектларын эксплуатацияләгәндә гамәлгә ашырыла торган товарларга, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тарифларны дәүләт җайга салуы карала торган дәүләти-хосусый партнерлыкның проектларын башкарганда, килешүнең гамәлдә булу вакыты дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салу өлкәсендәге вәкаләтле органы һәм хосусый партнер арасында өчьяклы озак сроклы тариф килешүе (алга таба – тариф килешүе) төзелергә мөмкин. Тариф килешүендә хосусый партнерның килешү объектын эксплуатацияләве

чорына бәяләр (тарифлар, аларга өстәмәләр) билгеләү һәм кую тәртибе, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салу өлкәсендәге вәкаләтле органы әзерли һәм раслый торган озак сроклы тариф сценарие, шулай ук, озак вакытлы тариф сценариенда каралган диапазон чикләреннән чыга торган тарифлар билгеләнгән очракта, хосусый партнерга компенсацияләр бирү механизмы каралырга тиеш.”;

5) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

“$1^1$. Татарстан Республикасы исеменнән концессия килешүләре “Концессия килешүләре турында” Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган тарафыннан төзелә.”;

6) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11 статья. **Коллегиаль киңәшү органы**

Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү, килешүләрне гамәлгә ашыруны һәм Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләрне хәл итүне мониторинглауны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча коллегиаль киңәшү органы башкара.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 9 июне
№ 46-ТРЗ